БУГУЛЬМИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
IV СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
IV ЧАКЫРЫЛЫШ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2025 ел г. Бугульма № 4

**УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ СЕССИЯСЕ**

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 14 августындагы Бөгелмә шәһәр Советының XXIV сессиясенең 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә таянып һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында

**Бөгелмә шәһәр Советы
карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 14 августындагы Бөгелмә шәһәр Советының XXIV сессиясенең 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| *Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары* | *Вазыйфаи оклад, сум* | |
|---|---|---|
| | *Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен* | *Муниципаль учреждениенең структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен* |
| Структур бүлекчә җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 39 800 |
| Бүлек башлыгы | 33 500 | 33 500 |
| Алып баручы бухгалтер | 29 500 | 29 500 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 29 500 | 29 500 |
| Бухгалтер | 27 800 | 27 800 |
| Икътисадчы | 27 800 | 27 800 |
| Хокук мәсьәләләре буенча белгеч | 27 800 | 27 800 |
| Система администраторы | 27 800 | 27 800 |
| Кадрлар буенча белгеч | 27 800 | 27 800» |

2) Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| *Вазифа* | *Вазыйфаи оклад, сум* |
|---|---|
| Баш бухгалтер | 29 700 |
| Бухгалтер | 27 000» |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Бөгелмә шәһәре мэры урынбасары** **И.Б.Белова**